РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021 елның 21 мае 148№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә торак урыны мәйданын бирү һәм исәпкә алу нормасын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган торак урыны гомуми мәйданының 12 кв.метрдан да ким булмаган күләмендә билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын бер гражданга торак урынның гомуми мәйданы 18 кв. метр күләмендә билгеләргә.

3. Дәүләт торак программалары буенча гражданнар милкенә торак урыны мәйданы бирү нормасын билгеләргә:

бер кешегә торак урынның гомуми мәйданыннан 33 кв. метр;

ике кешедән торган гаиләгә торак урынның гомуми мәйданыннан 42 кв. метр;

өч һәм аннан күбрәк кешеле гаиләгә һәр кешегә торак бинаның гомуми мәйданнан 18 кв.метр.

4. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

5. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының 2007 елның 26 декабрендәге «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак мәйданы нормалары турында» 394 а номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов